| МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **РАСПОРЯЖЕНИЕ** | | **БОЕРЫК** |
| 17.09.2014 | Казан ш. | № 1938-р |

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 16.09.2013 ел, №2832-р боерыгы белән расланган Торакны махсус торак фонд составына кертү һәм аның составыннан чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 16.09.2013 ел, №2832-р боерыгы белән расланган Торакны махсус торак фонд составына кертү һәм аның составыннан чыгару буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлектә:

а) 1.3.1 пунктта “69а,” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

б) 1.4 пунктка түбәндәге эчтәлектәге бишенче абзац өстәргә:

“Дәүләт күчемсез милек кадастры турында” 24 июль, 2007 ел, №221-ФЗ Федераль закон (алга таба - №221-ФЗ Федераль закон) (РФ законнар җыентыгы, 30.07.2007, №31, 4017 ст);”;

в) 1.7 пунктның “ж” пунктчасын төшереп калдырырга;

2) 2 бүлектә:

а) бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты”;

б) бүлектәге таблицаның беренче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләп атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт”; |

в) 2.3 пунктның икенче баганасына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү кәгазе”;

г) 2.5 пунктта:

икенче баганасына түбәндәге эчтәлектәге абзацлар өстәргә:

“техник паспорт;

торакның үзенә карата куела торган таләпләргә туры килүе турында бәяләмә.”;

өченче баганага “РФ ЖК”; №221-ФЗ Федераль закон; №42 РФ Хөкүмәте карары; №475 ТР МК карары; Нигезләмәнең 3.3.56 п.”;

д) икенче баганада 2.8 пунктның 2 пунктчасында “, эчтәлеген дөрес итеп аңлау мөмкинлеге бирмәгән җитди зыян килүләр” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

е) 2.15 пунктның икенче баганасына түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац өстәргә:

“-дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу срогын үтәү;”;

3) 3 бүлектә:

а) бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрн рәвештә административ процедураларны (гамәлләр) үтәү

үзенчәлекләре, шулай ук күп функцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре”;

б) 3.1.1.пунктның 3 пунктчасына “яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында белдерү кәгазе.” дигән сүзләр өстәргә;

в) 3.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү һәм ярдәм итә, шул исәптән тапшырыла торган документларның составы, аларны рәсмиләштерү һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне алу өчен башка мәсьәләләр буенча.”;

г) бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.4.1[1] пунктны өстәргә:

“ 3.4.1[1]. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре ведомствоара электрон хезмәттәшлек аша алынган 3.4.1 пунктта күрсәтелгән запрослар нигезендә, соралган документларны (мәгълүматлар) билгеләнгән срокта тапшыра.

Процедуралар нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булып торган документларны, мәгълүматларны яки баш тарту турында белдерү кәгазен Министрлыкка җибәрү.”;

д) бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 3.4.11 пунктны өстәргә:

“3.4.11. Дәүләт хезмәте электрон рәвештә һәм күп функцияле үзәк аша күрсәтелми.”;

4) 4 бүлекнең 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“4.4. Гражданнар, аларны берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдәге эшчәнлегенең ачыклыгы нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүне алу тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге нигезендә хәл ителә.”;

5) 5 бүлектә:

а) 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.3. Шикаять почта аша, күп функцияле үзәк аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.”;

б) 5.4 пунктның 1 пунктчасында “запросның” дигән сүзне “мөрәҗәгатьнең” дигән сүзгә алыштырырга;

в) бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5.10 пунктны өстәргә:

“5.10. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.”;

6) Административ регламентка кушымтада (белешмә) “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, икътисад, финанс һәм дәүләт милке белән эш итү идарәсе” бүлегендә таблицаның өченче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “Дәүләт милке белән идарә итү бүлеге начальнигы<br>Рогожкин Максим Анатольевич | 264-76-22 | Maksim.Rogozhkin@tatar.ru”. |

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары С.А.Демидовка йөкләргә.

**Министр** **А.К.Хамаев**